МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от «30» 12. 2015 № 491

Зарегистрировано
27.01.2016 № 3184

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының
аерым боерыкларының
үз көчләрен югалтуын тану турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

“Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен раслау турында” 2007 елның 11 июлендәге 59 номерлы боерык;

“Татарстан Республикасы Пассажирлар йөртүгә идарә итү үзәге турында нигезләмәне раслау хакында” 2007 елның 14 сентябрендәге 75 номерлы боерык;

“Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара даими маршрутлар буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы йөртүчеләр реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен раслау турында” 2007 елның 14 сентябрендәге 77 номерлы боерык;

“Гомуми файдаланудагы транспортның яңа маршрутларын ачу, гамәлдәге даими маршрутларында автобуслар хәрәкәтен вакытлыча үзгәртү, чикләү яисә

туктату тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 2007 елның 27 декабрендәге 111 номерлы боерык;

“Гомуми файдаланудагы автомобиль транспортының муниципаль һәм муниципальара даими маршрутларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатының тармак төбәк нормативларын раслау турында” 2008 елның 16 гыйнварындагы 3 номерлы боерык;

“Маршрут карталарын исәпкә кую, бирү һәм кире алу тәртибе турында” 2008 елның 21 апрелендәге 37 номерлы боерык;

“Татарстан Республикасында автовокзаллар, пассажир автостанцияләре эшчәнлеген оештыру буенча методик рекомендацияләрне һәм Муниципальара маршрутларда автовокзалларның, пассажир автостанцияләренең пассажирларга хезмәт күрсәтүе буенча үрнәк шартнамәне раслау турында” 2008 елның 2 декабрендәге 119 номерлы боерык;

“Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы автомобиль транспортының муниципальара маршрут челтәрен раслау турында” 2014 елның 11 декабрендәге 411 номерлы боерык.

Министр Л.Р. Сафин